ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Оешмалар мөлкәтенә салым турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 30 октябрендә
кабул ителде

## 1 статья

“Оешмалар мөлкәтенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш); 2013, № 3, № 6 (II өлеш), № 10, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“2. Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә салым ставкасын, күчемсез мөлкәтнең аерым объектларының салым базасын билгеләү үзенчәлекләрен, салымны түләү тәртибен һәм срокларын, шулай ук салым ташламаларын һәм салым түләүчеләрнең алардан файдалану нигезләрен билгели.”;

2) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ статья өстәргә:

“$1^1$ статья. **Күчемсез мөлкәтнең аерым объектларына карата салым базасын билгеләү үзенчәлекләре**

1. Халык саны 145 мең кешедән артык булган торак пунктлар территорияләрендә урнашкан гомуми мәйданы 3000 квадрат метрдан артык сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата салым базасы аларның билгеләнгән тәртиптә расланган кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә.
2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектлары исемлеге Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәт

мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясы нигезендә билгеләнә.";

3) 2 статьяда:

а) 1 өлештә "әлеге статьяның 2 өлешендә" сүзләрен "әлеге статьяда" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

"3. Салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата салым ставкасы 2015 елда – 1,2 процент, 2016 елда – 1,5 процент, 2017 елда – 1,8 процент, 2018 елда һәм аннан соңгы елларда 2 процент күләмендә билгеләнә.";

4) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

"4. Салым түләүчеләргә әлеге статьяда билгеләнгән салым ташламалары салым базасы кадастр бәясенә тәңгәл билгеләнә торган күчемсез мөлкәт объектларына карата бирелми.";

5) 5 статьяда:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) 2015 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктын, 3 өлешенең 1 пунктын;";

б) түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

"7) 2018 елның 1 гыйнварыннан әлеге Законның 3 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктын, 2 өлешенең 5, 8 пунктларын, 3 өлешенең 2, 4 пунктларын.".

**2 статья**

Әлеге Закон 2015 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 30 октябре
№ 81-ТРЗ